ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**03.05.2018**

Зеленодольск шәһәре

**КАРАР**
**№ 1020**

Массакүләм спорт һәм ачык чаралар уздыру вакытына гомуми файдаланудагы юлларны вакытлыча ябып тору турында

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә Бөек Ватан сугышында Җиңүнең еллыгын бәйрәм итү вакытында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатыннан, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. 2018 елның 09 маенда Зеленодольск шәһәренең җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларының түбәндәге участокларында 08.00 сәгатьтән 15.00 сәгатькә кадәр бәйрәм массакүләм чараларын үткәрү чорында җәяүлеләр зонасын оештырып транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча туктап торуны гамәлгә ашырырга:

- Заикин урамы чатыннан алып Беренче Май урамы чатына кадәр Ленин урамын;
- Карл Маркс урамы чатыннан алып Ленин урамы чатына кадәр Татарстан урамын

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск районы буенча ЭЭМ бүлегенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- әлеге карарның 1 пункты нигезендә Зеленодольск шәһәрендә бәйрәм массакүләм чараларын үткәрүне тәэмин итү өчен барлык төр транспорт чаралары хәрәкәтен туктатып торуны оештырырга;
- бәйрәм барышында катнашучыларның һәм тамашачыларның иминлеген тәэмин итү, аларны үткәрү чорында транспорт хәрәкәтен җайга салу буенча кирәкле чаралар күрергә;
- чаралар уздыру урыннарына якын урамнар участокларындагы оператив хәлне исәпкә алып, транспорт хәрәкәтен чикләү яки ябу буенча карарлар кабул итәргә.

3. Пассажирлар транспорты хәрәкәтен «Зеленодольск муниципаль районының төзелеш һәм инфраструктура үсеше департаменты» МБУ Зеленодольск шәһәренең Карл Маркс урамында оештырырга.

4. ЗМР Советы аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгы Д.С.Анисимовка әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга һәм массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин